**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№236 06.02.2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын раслау турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып, ачык тыңлаулар беркетмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 23 декабрендәге 10-53/16060 номерлы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Аксубай район халык депутатлары Советы Президиумының «р.п. Аксубай планировкасы проекты белән берләштерелгән генераль план турында» 2005 елның 16 февралендәге карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatar.ruһәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе К.К. Гилманов